Татарстан Республикасы

Балык Бистәсе муниципаль районы

Уракчы авыл җирлеге Советы

**КАР**
**АР**
**№**
**14**

Уракчы авылы 2017 елның 27

сентябре

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча Уракчы авыл җирлеге территориясендә җирле референдум билгеләү турында

2002 елның 12 июнендәге "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" 67- ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсенә, 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131- ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 маддәләренә, 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы законының 20 маддәсенең 1 өлеше 1 пунктына, 2004 елның 24 мартындагы "Җирле референдум турында" 23-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы законының 12 маддәсенең 1 пункты "в" пунктчасына, 18 маддәсенә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Уракчыавыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 11 маддәсенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчыавыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 21 сентябрендәге "Референдум үткәрү инициативасы турында" 21 номерлы карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлеге Советының 2017 елның 21 сентябрендәге "Референдум үткәрү инициативасы турында" 17 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчыавыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчыавыл җирлеге территориясендә 2017 елның 19 ноябренә җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарылучы түбәндәге сорауны расларга:

"Яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе

муниципаль районы Уракчыавыл җирлеге территориясендә теркәлгән балигъ булган, уку йортларының көндезге бүлекләрендә укучы студентлардан гайре, һәрбер кешенең 2018 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертүенә һәм җыелган средстволарның түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә:

- Чаллы-Баш ш. п., Околоток-Янгасалның энергияне сак тотучы лампаларына урам яктырткычларын алыштыру;
- Уракчы авылында су башнясы өчен тирән насос сатып алу;
- Уракчы авылында артезиан скважинасының санитар-саклау зонасын төзү;
- Уракчы авыл җирлеге чикләрендә кышкы юлларны карап тоту.

Сез ризамы?

ӘЙЕ

Ю

К".

3. Әлеге карарның рәсми рәвештә игълан ителгән көннән үз көченә керүенбилгеләргә.

4.Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчыавыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Уракчы авылы, Совет урамы, 36Айорт; Мельничный Пүчинкәсе авылы, Киров урамы, 20Б һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсмипорталы"ында урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Уракчы авыл җирлеге Башлыгы Ф.М.Гәрәев